


***ГАБДУЛЛА ТУКАЙ –***

***ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ БӨЕК ШАГЫЙРЕ***

***1886-1913***

Халкым күңеленә ак нур сиптең,
Кара төндә булдың якты ай;
Шаулы язның сүнмәс тугаедай,
Мәңге дәртле җырчы син, Тукай!

Галиева Лилия Альберт кызы татар теле һәм әдәбияты укытучысы.



Мөхәммәтгариф – Габдулланың атасы



Мәмдүдә - Габдулланың анасы.



Габдуллаҗан Мөхәммәтгариф улы Тукаев

1886 елның 13 (26) апрелендә, Казан өязе,

Мәңгәр волосте, Кушлавыч авылында,

мулла гаиләсендә туа.



Кечкенә Тукай дүрт айда әтисез, дүрт яшьтә әнисез кала. Ятимлек ачысын бик иртә татый.

- Тормыш аны, тәпи басу белән,
- Җитәкләде ике кулыннан;
- Җитәкләде язмыш, кай җирләргә
- Алып чыгар авыр юлыннан

Дөм ятим Габдулланы 1890 елда Өчиле авылына  бабасы Зиннәтулла йортына кайтарып куялар. Булачак шагыйрьнең шактый караңгы көннәре шунда үтә.





-Бик тиз генә борылып кайта алмам,
Сезне борчып монда килмәсләр,
Хуш, кадерле нигезем, ак каеным,
сау булыгыз, шомырт, миләшләр!

Тукайның әнисенең сеңлесе Сажидә. 1940 нчы елда төшерелгән фоторәсем.

Кечкенә Габдулланы бервакыт Өчиледән Казанга алып киләләр дә Печән базарында берәр кешегә асрамага бирмәкче булалар. Яңа Бистәдә яшәүче Мөхәммәтвәли белән Газизә апаның балалары юк икән: ятим Габдулланы алар уллыкка алалар.



Базар күрсә,  безнең Габдулланың
Йөрәгендә әрнү кузгала :
Колагында чыңлый ямщик тавышы;
“Асрамага бала кем ала?”

Ләкин бу бәхет озакка бармый: Мөхәммәтвәли абзый белән Газизә апа икесе берьюлы авырый башлыйлар. Малай яңадан Өчилегә кайтарыла. 1892 елның җәендә Кырлай авылы крестьяны Сәгъди абзый аны үзенә уллыкка ала.



**Тукайның Өчиледән Кырлайга китүе**

Кырлай авылы. Сәгъди абзый йорты. Хәзер анда Тукай музее - йорты





Печән өсте. Бәләкәй Апуш белән Сәгъди абзый Кырлай болынында.

- Сәгъди абзый   йорты бик тәбәнәк,
- Салам белән япкан түбәсен
- Шаулап үскән нарат урманнары
- Аның өчен түгел, күрәсең.



1894 елда Габдулла Җаекка, Уральск шәһәренә әтисе ягыннан туган Газизә апасы һәм аның ире Галиәсгар Госманов янына күчеп килә һәм Почталинин урамы, 66нчы йортта яши башлый



1895 – 1898 нче елларда Тукай укыган өч класслы рус мәктәбе бинасы.



صحيفه ـ ۱

1904 ... 15

العصر جديد

مجلس علميه

Кулъязма “Әлгасрелҗәдид” журналының тышлык бите. Бу журналны мәдрәсәдә укыган вакытта Габдулла иптәшләре белән чыгарган. Журналның һәр бите Габдулланың үз кулы белән язылган.



Тукайның журналистик эшчәнлеге Камил Мотыйгый белән бергә башлана. 1906 – 1907 елларда Мотыйгый “Фикер” газетасын һәм “Әлгасрелҗәдид”, “Уклар” журналларын чыгара. Тукай дусты Камил Мотыйгый белән Уральскида.



**1907** елда  Г. Тукай ашкынып, “дәртле”, “моңлы”, “нурлы” Казанга кайта

*Кечкенә генә булса да үз фатиры булмаганга күрә, ул “Болгар” һәм “Амур” кебек кунакханәләрдә яшәргә мәҗбүр булган. Шушы җайсызлыкларга үч итеп, үҗәтләнеп иҗат иткән, каләмен уләренә бер тәүлек кала гына читкә куйган.*



№ 3   ١٧ اوكتابر ١٩٠٧ سنه   چهارشنبه   ٢٣ رمضان ١٣٢٥ سنه

اخطار:

غزيتهنڭ بهاسى

آدرس:
Казань, Номера „БОЛГАРЪ“
Редакція газ. „ЭЛЬИСЛАХЪ“
Телефонъ № 748

ЕЖЕНЕДѢЛЬНАЯ ГАЗЕТА
„ЭЛЬ-ИСЛАХЪ“

علمى ادبى مفكلك غزيته



“Әль – ислах” газетасын чыгаручылар. Сулдануңга: Вафа Бәхтияров, Кәбир Бәкер,Фатих Әмирхан,Ибраһим Әмирхан һәм Габдулла Тукай.



Габдулла Тукай. 1912 елгы фоторәсем. Бу вакытта инде Тукай халык тарафыннан танылган шагыйрь һәм публицист. Аның егерме бишләп китабы чыккан, аның әсәрләре матбугатта даими рәвештә чыгып тора, ул һәрвакыт халык игътибарында

Бик ерактан сызылып аткан
Бер гүзәл апрель таңы
Бирде сине бу җиһанга
Әй, шагыйрьләр солтаны!

Мостафа Ногман




*Тукай сабый вакытыннан ук халык җырларын*

*ярата, аларны хәтеренә сеңдерә, язып бара.*

*1910 елда ул “Шүрәле” псевдонимы белән “Халык моңнары”*

*исемендә татар халык җырлары җыентыгын бастыра.*




1909 елда Тукай үзенең үткән балачагы турында “Исемдә калганнар” дигән автобиографик повесть яза.

Шагыйрь исән вакытта ук басылып чыккан повестьның беренче битләре.




КИТАП шигыренең кулъязмасы.

Г.Тукай Клячкин шифаханәсендә.

1913 ел, 14 (1) апрелендә төшерелгән фоторәсем.



***Үлем түшәгендә ятканда да Г. Тукай үзенең чын мәгъләсендә шагыйрь һәм үз халкының патриоты икәнлеген исбат итте. Соңгы минутларда да ул халкы өчен җитәрлек эш башкара алмавына көенә.***

Кыска булды гомер юлы, иртә сынды моңлы сазы:
Шат яз бүләк итте аны, алып китте кайгы язы...




***Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай***

***1913 елның 15 (2) апрелендә кичке 8 сәгать 15 минутта күзләрен мәңгегә йома .***

**1913 елның 17(4) апрелендә Габдулла Тукайны җир куенына озаталар**

Үлемсездер ләкин Кодрәт, бүген дә яши – ул Тукай,
Вакыт үтсә дә сүнми бит күктә балкыган ярым ай

***Тукай дөньяда 27 ел гына яшәсә дә, искиткеч зур әдәби мирас калдырды, халыкка хезмәт итүнең бөек үрнәген бирде. Шагырьнең шигырь һәм поэмалары, мәкалә һәм хатлары, очерк һәм фельетоннары бүген дә әле безнең замандаш булып яшиләр, халык йөрәгенең “иң нечкә кылларын” тибрәтәләр.***

